**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**
**III ЧАКЫРЫЛЫШ XLVIII СЕССИЯСЕ**

**КАРАР № 2**

Югары Табын авылы «03» февраль 2020 ел

**Түбән Табын авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 декабрендәге 3 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Түбән Табын авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның 10 декабрендәге 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктның 1 пунктчасының 3 абзацын төшереп калдырырга;

б) 2 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,1 %;»

1. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан җир салымын исәпләүгә бәйле рәвештә хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

***Түбән Табын* авыл җирлеге Башлыгы:** ***Р.Ш. Кыяметдинов***